КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 август г.Казань № 987

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 ноябрь, 1086 нчы; 2022 ел, 8 сентябрь, 968 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы; 2023 ел, 17 май, 604 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык

субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктның өченче абзацында татар текстында «заявка биргән» сүзләреннән соң «, элек бу грантны алмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Грант заявка бирүчеләрнең проектны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләре:

торак булмаган урынны арендалау;

торак булмаган урынны ремонтлау (урынны ремонтлау өчен кирәкле төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алуны кертеп);

оештыру техникасы, җайланма (шул исәптән инвентарь, җиһаз) сатып алу һәм (яисә) аларны арендалау;

франшизага хокукларны тапшыру буенча түләү (паушаль түләү);

инженерлык инфраструктурасы объектларына технологик тоташтыру (электр челтәрләре, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су чыгару, җылылык белән тәэмин итү);

коммуналь хезмәтләр һәм электр белән тәэмин итү хезмәтләре өчен түләү;

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

төп чараларны сатып алу (биналар, корылмалар, җир кишәрлекләре, автомобильләр сатып алудан тыш);

аз хәрәкәтләнә торган халык төркемен, шул исәптән инвалидларны йөртү өчен транспорт чараларын яңадан җиһазлау;

элемтә, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре хезмәтләре өчен түләү;

массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә проект булдыру, аңа техник ярдәм күрсәтү, анда мәгълүмат урнаштыру, аны үстерү һәм тарату хезмәтләре өчен түләү (хостинг хезмәтләре, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә домен исемнәрен теркәү һәм теркәүне озайту чыгымнары, эзләп табуны оптимальләштерү чыгымнары, социаль челтәрләрдә сайтны һәм аккаунтларны модернизацияләү һәм (яки) тарату хезмәтләре һәм (яки) эшләре);

программа тәэминатын һәм программа тәэминатына махсус булмаган хокуклар сатып алу (лицензия килешүе буенча хокуклар алуга бәйле чыгымнар; программа тәэминатын җайлаштыру, көйләү, кулланышка кертү һәм модификацияләү чыгымнары; программа тәэминатының эшләвен тәэмин итү чыгымнары);

продукция җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле чимал, чыгым материаллары сатып алу;

лизинг шартнамәсен төзегәндә беренче кертем (аванс) һәм (яки) лизинг түләүләрен түләү (әгәр шартнамә предметы транспорт чарасы булса, лизинг, сублизинг шартнамәсе буенча беренче кертем (аванс) һәм лизинг түләүләре өчен

түләүдән тыш);

яңа коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау чараларын (санитария-эпидемиология таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә бәйле чараларны кертеп) гамәлгә ашыру.

Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына өстәмә рәвештә грант медицина техникасы, протез-ортопедия эшләнмәләре, программа тәэминаты җитештергәндә һәм (яки) реализацияләгәндә комплектлау әйберләре, шулай ук инвалидлыкны профилактикалау яки инвалидларны реабилитацияләү (абилитацияләү) өчен генә файдаланыла алган техник чаралар сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Заявка бирүче түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 1нче көненә:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара;

Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

заявка бирелгән датага кече яки урта эшкуарлык субъекты булып тора;

социаль эшкуарлык реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә социаль предприятие дип танылган һәм аның турында мәгълүмат агымдагы календарь елның 10 июленнән 31 декабренә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән;

беренче тапкыр социаль предприятие буларак танылган һәм социаль эшкуарлык өлкәсендә эшчәнлек алып бару юнәлеше буенча грант алу өчен документлар тапшырган датага кадәр ел дәвамында укыту программасы яки акселерация программасы кысаларында укыган яки социаль предприятие статусын раслаган, грант алу өчен документлар тапшыру датасына элек булдырылган проектны гамәлгә ашыра;

25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

кече һәм урта эшкуарлык субъекты 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат тарафыннан төзелгән (грант алу өчен документлар тапшыру датасына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат индивидуаль эшкуар яки юридик зат буларак теркәлгән, 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) бер яки берничә физик затның устав (җыелма, акционерлык) капиталында катнашу өлеше (суммар өлеше) 50 проценттан арткан);

кече һәм урта эшкуарлык субъекты (әлеге пунктның унынчы абзацына туры килә торган) һәм (яки) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлаган вакытта кызыксынучы физик зат эшкуарлык эшчәнлеген алып бару юнәлеше буенча грант алу өчен документлар тапшырган датага кадәр ел дәвамында укыту программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булган.»;

3.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият

кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазен яки 2023 елның 1 гыйнварыннан сайлап алу үткәрергә планлаштырыла торган айның 1 нче көненә кадәрге чор өчен Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон рәвештә бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 30 ноябрендәге ЕД-7-8/1129@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым органы биргән салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында белешмә кәгазе;»;

4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Грант бер грант алучыга кимендә 100 000 сум һәм иң күбе 500 000 сум бирелә.

Грант проектны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар грант алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән һәр чыгым юнәлеше буенча мондый проектны гамәлгә ашыруга каралган чыгымнар күләменнән кимендә 25 процент күләмендә финанслашу шарты белән бирелә.

Сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган грант күләме (Г) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Г = РРП – СС,$$

монда:

РРП – әлеге Тәртипнең 1.4 пункты нигезендә проектны гамәлгә ашыруга каралган чыгымнар;

СС – сайлап алуда җиңүче тарафыннан проектны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслашу суммасы.

Грант кабат, әмма билгеләнгән күрсәткечләргә ирешелгән очракта килешү төзелгән вакыттан өч елга кимендә бер тапкыр бирелергә мөмкин.»;

4.9 пунктның сигезенче абзацында «бишенче» сүзен «җиденче» сүзенә алмаштырырга;

5.7 пунктның унберенче абзацында «ел саен» сүзләреннән соң «10 июльгә кадәр» сүзләрен өстәргә;

5.11 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри керемгә салым түләүче грант алучылар өчен – Федераль салым хезмәтенең «Һөнәри керемгә салым буенча белешмә кәгазьләре турында һәм Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 5 июнендәге СД-4-3/10848@ номерлы хаты үз көчен югалткан дип тану хакында» 2023 елның 5 маендагы СД-4-3/5763@ номерлы хаты нигезендә электрон төрдә булдырылган һөнәри керемгә салым буенча исәп-хисаплар (керемнәр) торышы турында белешмә кәгазе (КНД 1122036).»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Социаль эшкуарлар реестрына
кертелгән кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә
кадәрге (25 яшьне кертеп) физик
затлар тарафыннан төзелгән кече һәм
урта эшкуарлык субъектларына
субсидияләр рәвешендә грантлар бирү
тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 август, 987 нче
карары редакциясендә)

Форма

## Гарантия хаты

___________________________________________________________________
(юридик затның исеме, индивидуаль эшкуарның Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

(алга таба – заявка бирүче)______________________________________________ йөзендә,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

________________________________ ___________________________нигезендә эш итүче,
(устав, Шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРИП) таныклыгы, ышанычнамә реквизитлары)

монның белән конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 1нче көненә түбәндәгеләргә гарантия бирә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле 3 мең сумнан арткан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавына;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмавына;

заявка бирүченең юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның заявка бирүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавына, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәвенә, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавына, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшкуар үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмавына;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор

компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процenttан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавына. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенең (алга – Тәртип) 1.4 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавына.

Конкурста сайлап алуның түбәндәге критерийларына туры килүенә өстәмә гарантия бирә:

конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 1 нче көненә:

заявка бирүче Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара;

заявка бирүче Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

заявка бирүче заявка биргән датага кече яки урта эшкуарлык субъекты булып тора;

социаль эшкуарлык реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә социаль предприятие дип танылган һәм аның турында мәгълүмат агымдагы календарь елның 10 июленнән 31 декабренә кадәрге чорда кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән;

беренче тапкыр социаль предприятие буларак танылган һәм социаль эшкуарлык өлкәсендә эшчәнлек алып бару юнәлеше буенча грант алу өчен документлар тапшырган датага кадәр ел дәвамында укыту программасы яки акселерация программасы кысаларында укыган яки социаль предприятие статусын раслаган, грант алу өчен документлар тапшыру датасына элек булдырылган проектны гамәлгә ашыра;

25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

кече һәм урта эшкуарлык субъекты 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат тарафыннан төзелгән (грант алу өчен документлар тапшыру датасына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат индивидуаль эшкуар яки юридик зат буларак теркәлгән, 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) бер яки берничә физик затның устав (җыелма, акционерлык) капиталында катнашу өлеше (суммар өлеше) 50 проценттан арткан);

кече һәм урта эшкуарлык субъекты (Тәртипнең 2.2 пунктындагы унынчы абзацына туры килә торган) һәм (яки) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлаган вакытта кызыксынучы физик зат эшкуарлык эшчәнлеген алып бару юнәлеше буенча грант алу өчен документлар тапшырган датага кадәр ел дәвамында укыту программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булган.

___________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)
20___ ел, «___» __________